РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

19.08.2021 | № 993-п

“2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы” муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы” муниципаль программасын раслау турында” 2019 елның 6 мартындагы 204-п номерлы карары белән расланган “2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы” муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның паспорты таблицасында “Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2019-2023 елларда Программаны финанслау барлыгы 70,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 ел - 0,000 мең сум;<br>2020 ел - 0,000 мең сум;<br>2021 ел - 70,000 мең сум;<br>2022 ел - 0,000 мең сум;<br>2023 ел - 0,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәллләштереләчәк. |

“;

1.2. “Муниципаль программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү” 14 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**“14. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү**

Муниципаль программа чаралары Саба муниципаль районы бюджеты акчалары һәм башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла. 2019-2023 елларда муниципаль программаны финанслауның планлаштырылган гомуми күләме 70,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 ел - 0,000 мең сум;
2020 ел - 0,000 мең сум;
2021 ел - 70,000 мең сум;
2022 ел - 0,000 мең сум;
2023 ел - 0,000 мең сум.

Муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү нигезендә һәм чираттагы финанс елына Саба муниципаль районы бюджетының расланган бюджет ассигнованиеләреннән һәм бюджет йөкләмәләре лимитларыннан чыгып ел саен ачыкланырга мөмкин.

Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итү турында мәгълүмат муниципаль программага 3 кушымтада бирелгән.

Саба муниципаль районы Татарстан Республикасы һәм федераль бюджетлар акчалары хисабына кече һәм урта бизнеска ярдәм итү кысаларында субсидияләр алучы дип танылган очракта, әлеге акчалар муниципаль программаны финанслау чыганагы буларак карала.».

1.3. Программаның 3 кушымтасын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.И. Котдусовка йөкләргә.

ТР Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның
19 августындагы 993-п номерлы
карарына 1 кушымта

“2019-2023 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районында кече һәм урта
бизнесны үстерү программасы” муниципаль
программасына 3 кушымта

## “2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы” муниципаль программасын гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

| № т/б | Муниципаль программа, өстәмә программа, аерым чара исеме | Җаваплы башкаручы, башкаручылар | Чыгымнар мең сум, еллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы» муниципаль программасы | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инвестиция һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| | Кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләре өчен семинарлар, күргәзмәләр һәм конференцияләр үткәрү, тарату материаллары әзерләү | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инвестиция һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге | 0,000 | 0,000 | 70,000 | 0,000 | 0,000 |